КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1122

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 421 нче карары белән расланган Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 421 нче карары белән расланган Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет чаралары алучысы буларак билгеләнгән тәртиптә Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм мәгълүмат чаралары агентлыгына (алга таба – акча белән баш эш итүче) бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның беренче көненә оешма түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

оешманың Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;

оешма үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел;

оешма чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (оффшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты түгел;

оешма агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаган.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Субсидия күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6 + З_7,$$

монда:

С – оешмага бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$ – оешманың штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә акча тоту;

$З_2$ – бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен түләүгә акча тоту;

$З_3$ – җитештерүдә бәхетсез очраклардан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча оешманың кертемнәрен түләүгә акча тоту;

$З_4$ – чыгым материаллар сатып алуга акча тоту;

$З_5$ – авторлык һәм эргәдәш хокуклар буенча түләүләргә, архив материалларын, компьютер графикасын файдалануга акча тоту;

$З_6$ – элемтә хезмәте күрсәтүләрне түләүгә акча тоту;

$З_7$ – типография хезмәте күрсәтүләрне түләүгә акча тоту.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Басмага әзерләүне, социаль әһәмияттәге әдәбиятны бастырып чыгару һәм таратуны гамәлгә ашыручы оешма субсидия алу өчен акча белән баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

акча белән баш эш итүче билгеләгән форма буенча, чыгымнарның исәп-хисапларын һәм нигезләүләрне теркәп, субсидия бирү турында гаризаны;

оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) имзасы һәм мөһере (булганда) белән таныкланган гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләрне кертү турында документлар күчермәләрен (карап чыгу өчен төп нөсхә);

оешманың штат җәдвалын;

агымдагы елда социаль әһәмияттәге әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм таратуны оештыру буенча чаралар планын;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә оешманың туры килүен раслый торган документларны;

узган финанс елына бухгалтер балансын;

субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениесендә ачылган исәп-хисап счетының реквизитлары күрсәтелгән, оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) һәм баш хисапчысы имза куйган, оешма мөһере белән беркетелгән (булганда) белешмәне;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән, оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) һәм баш хисапчысы имза куйган, оешма мөһере белән беркетелгән (булганда) чыгымнар сметасын;

социаль әһәмияттәге әдәбиятны бастырып чыгару белән бәйле чыгымнарны раслый торган документлар күчермәләрен: шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счетлар, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган исәп-хисап кәгазьләре.

Документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында тапшырыла ала.

Оешма үз башлангычы белән вәкаләтле органга оешманы салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен тапшырырга хокуклы. Әлеге документ күчермәсе оешма башлангычы белән тапшырылмаган очракта вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органыннан соратып ала.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Акча белән баш эш итүче субсидия бирү турында гаризаны һәм оешма тапшырган документларны керү тәртибендә журналга терки, ул кергән көнендә шнурланган, сан сугылган һәм вәкаләтле органның мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

Акча белән баш эш итүче 30 календарь көне эчендә субсидия бирү турында гаризаны һәм аңарга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

оешма тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

оешма тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң җиде эш көне эчендә акча белән баш эш итүче оешмага караның күчермәсен һәм субсидия бирү турында килешү проектын җибәрә. Оешмадан ул имза куйган килешүне алган көннән соң җиде эш көне эчендә килешүгә акча белән баш эш итүче имза куя.

акча белән баш эш итүче субсидия бирү турында килешү проектын җибәргән көннән соң 20 календарь көне эчендә оешма имза куйган килешү акча белән баш эш итүчегә тапшырылмаса, әлеге оешмага субсидия бирү турында карар гамәлдән чыгарылырга тиеш.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Үрнәк формасын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән Субсидия бирү килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе;

аларны кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнар исемлеге;

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше һәм аны алу чыганагы;

субсидия күчерү вакытлары (вакыттан вакытка кабатлануы);

әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен оешма үтәүне акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан мәҗбүри тикшерү турында нигезләмә;

алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүен акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тикшерүне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш);

субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен субсидия алучының җаваплылыгы;

субсидия акчасы керү һәм тотуның аерым бухгалтер исәбен алып бару турында таләп;

акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр йомгаклары буенча субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта субсидияне кире кайтару тәртибе;

акча белән баш эш итүче билгеләгән субсидияне файдалану турында хисап бирү вакытлары һәм формалары.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән һәм оешма субсидия исәбеннән оешманың кире кайтарыла торган чыгымнары турында хисап тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә, акча белән баш эш итүче субсидияне оешманың Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениесендә ачылган исәп-хисап счетына күчерә.»;

14 пунктның беренче абзацында «билгеле булган» сүзләре алдыннан «акча белән баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр вакытында» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин